80 ЛЕТ НЕФТИ ТАТАРСТАНА

TATNEFT

75 ЛЕТ РОМАШКИНСКОМУ МЕСТОРОЖДЕНИЮ

# Произведения

## лауреатов I степени литературного конкурса

# «Место рождения нефти»

*Совместный проект*

*Компании «Татнефть» и Союза писателей РТ*

ББК 84(2Рос=Тат)-5

Произведения лауреатов I степени литературного конкурса «Место рождения нефти». – Казань: Рухият, 2023. – 40 с.

© Благотворительный Фонд «Татнефть», 2023

## Номинация
## «Проза на татарском языке»

***Факил Сафин***
*член Союза писателей РТ*

# БИШКА

*(Хикәя)*

Бишка… Бу сүз мине балачактан бирле озатып бара. Әлеге бик тә сәерсендергән сүзне беренче мәртәбә күрше Шәрифә ападан ишеттем.

Шәрифә апа – терәлеп торган күршебез, үзе әйткәнчә, яше утызга җитеп килүче мөлаем йөзле, тәмле сүзле, чибәр апа иде.

Кайчакларда, эштән бушаган вакытларда дип тә әйтә алмыйм, чөнки Шәрифә апаның буш вакыты булды микән – гел хәрәкәттә, нәрсәдер белән мәшгуль иде ул, үзе апа тавык фермасында эшли, тырышып эшләгәнен дә өйдәгеләрнең сүзләреннән белеп торам, әле үткән кыш Мәскәүнең үзенә чакырып, медаль тагып кайтардылар. Тик ни сәбәптер, шушы чибәр апабыз, кияүгә чыкмыйча, әнисе Сәхипҗамалтәй белән көн күреп яталар. Юк, аларны ятим-җилпе дип булмый, кайчандыр гаиләләре гөрләп торган, аннан ләгънәт сугыш гаиләне тәмам туздырып ташлаган: әтисе, ике абыйсы сугышта һәлак булганнар. Сәхипҗамал түти дә, Шәрифә апа да колхоз эшеннән кайтып кермиләр, тормышлары ул чор өчен ярыйсы гына җитешле иде дисәң дә була. Тик кияүгә чыгу мәсьәләсе генә… Аның тагын бер хикмәте бар – кияү килгәч, олы капканы мин ачарга тиеш идем, Шәрифә апа күптән әйтеп куйган иде, ә ул кияү юк дип зарланып йөрүдән бушамый. Капкаларын югыйсә йөз мәртәбә ачып, ябып карадым, мин әзер, апа әзер түгел.

Безгә кергән саен, сүз шушы катлаулы мәсьәлә тирәсендә бөтерелеп ала. Шәрифә апа диварга эленгән көзге каршысына килеп, күзләрен уйнаткалап ала да, кисәк кенә сорап куя:

– Мин чибәрме, Фәридун?

Мин беренче күргән сыман Шәрифә апага карап алам да, ике дә уйлап тормастан:

– Чибә-әр, Шәрифә апа, син бик чибәр, – дигән булам. – кайчан кияүгә чыгасың инде? – Шәрифә апа хәсрәтле көлемсерәп көзге каршыннан китеп бара. Минем тел төбемне аңлый инде – олы капка кайчан ачылачак?. Соравымның төбендә шул ята.

Шушы гөнаһсыз сүзләргә күңеле булып, Шәрифә апа кесәсеннән ирис конфеты чыгарып, минем учка сала.

– Рәхмәт, үскәнем, әле дә син бар күңелне күтәрергә, – дип, аркадан сөеп куя. – Бер дә кешедән ким-хур түгел дә… карт кыз булып утырып калам бугай инде… Утызга табан барганда… аннан кырык тулыр… Яшең җитсә кырыкка… – Шәрифә апаның күзендә моңлы әрнү пәйда була.

– Кая әле сиңа утыз тулу! – дип, сүзгә әнкәй кушыла. – Әйдә, чәй эчәргә утыр, көзге алдында серәеп торма. Егерме җиденче яшь кенә сиңа. Насыйбың чыкмый калмас, Аллаһ боерса.

– Насыйбы булыр иде дә… Авыл тулы яп-яшь тол хатыннар, минем ише насыйбын көтеп ятучы кыз-кыркын. Сугыш, каһәр суккыры, ир-атны чүпләп бетерде шул. Иң беренче сугыш утына шул сугышны башлаган кешене илтеп тыгар идем мин. Күпме хәсрәт, күпме кайгы ил өстендә. Әнә Кадим Галиясе, болай утырып калганчы дип, бер кыз табып куйды. Шәйхетдиннән диләр… Сәрбиназ да авырлы икән дигән сүз чыкты. Аптыраганнан инде, ялгыз калганчы ди торганнардыр. Әллә мин әйтәм…

Әнкәй күрше апаның сүзен кырт бүлдерә андый чакта.

– Кит, җүләр сүз сөйләмә! Авызыңнан җил алсын! Әйтәм бит, насыйбың чыгар, сабыр ит. Үзең дә инде. Өй тавыгы сыман, эштән кайтуга, кереп бикләнәсең. Клубка чыгып, яшьләр арасында йөрсәң…

Шәрифә апа, үз чиратында, әнкәйне бүлдереп куя:

– Бу яшьтәме? Нинди клуб ди безгә. Хәзер унбиш-уналты яшьлек кызлар егетләрнең башын әйләндерәләр. Минем ишеләргә караучы да юк. Әйтәм бит, утырып калулар язган бугай безләргә. – Шәрифә апа сөйләнә-сөйләнә өстәл

артына килеп чүмәшә. Мин уенга мавыгып, әнкәй белән икесенең тагынниләр гапләшкәнен ишетмим инде.

Шулай да, Шәрифә апаны, чибәр, юмарт күрше апасын чын-чынлап кызгана иде минем сабый акылым.

Аннан дөньялар көтмәгәнчә үзгәрде дә куйды. Миңа биш-алты яшьләр тирәсе булгандыр ул чакта. Димәк ки, бу 1959 елның яз айларына туры киләдер. Авылга нефтьчеләр килде.

Безнең йорт авыл читендәрәк әлләни озын да булмаган тар гына урамның урта өлешендә иде. Урамны элек тә, хәзер дә Сапыйлар урамы дип йөртәләр. Болай читтәге туганнардан килгән хатларның конверт тышларына Революция урамы дип куела торган иде. Сапый – Сафиулла мин күреп өлгерә алмаган Сафиулла бабай – кайчандыр туп-туры сузылган урамның Печмән елгасы ягына йорт салып кергән, тора-бара гаиләдә үскән ике егет тә башлы-күзле булып, кара-каршы йорт салып чыкканнар. Урамга Сапый атамасы чәпелеп калган. Менә шушы тыныч кына гомер кичереп яткан урамыбыз, яз ахырларында гомер бакый килгән тынычлыгыннан мәхрүм калды. Бу үзгәрешнең кайчан булганын төгәл беләм, чөнки язгы ташуның соңгы талпынышы Имәнлек урманыннан төшеп, безнең урам аша үтә иде. Миңа бу ташу суы диңгезгә тиң дәрья сыман тоела. Ташу суы урамыбыз буйлап көн-көн ярым шау килеп, дулап-актарылып ага иде андый чакта. Ташу басылгач, урам янә тын кала. Озак та үтми, каз бәбкәләре чыга башлый, көннәрнең берсендә ата казны биетә-биетә әнкәй каз оясына тулып бипелдәгән бәбкәләрне күтәреп, урамның югары башындагы яланга алып китә. Миңа үткән елда эш табылды, яландагы әбиләр белән бергәләп, мин дә үзебезнең бәбкәләрне саклап мәш килгән булдым. Менә шушы тын тормыш, кабат ташу төшкәннән дә битәр, төбе-тамыры белән актарылды – өйләрне тетрәтеп урамыбыздан галәмәт олы машиналар, тимер тавы кадәрле тракторлар үтә башлады. Андый чакта безнең җыйнак кына өебез дер селкенә, урыннан кубарылып, теге ата каз сыман биеп китәр сыман тоела иде. Кая урамга чыгу, бу хикмәттән качып, өйдә генә ятыш. Өйдәгеләр сөйләшкәннән колакка керә,

әткәй белән әнкәй Шөгер, Писмән, Бөгелмә, Әлмәт дигән минем колакка ят тоелган ниндидер шәһәрме, авылмы исемнәрен атыйлар. Нефть эзлиләр икән безнең баз астыннан. Әткәй шулай ди. Болар җирне бораулап, шул нефтьне чыгарырга йөрүчеләр, ди. Прәме безнең баз астында нефть диңгезе бар икән. Чапырыш күрше Мәхтүрә апа кергән иде, Имәнлек ягыннан авыл астыннан ташу суыннан да шәбрәк җир асты елгасы ага икән. Нефтьчеләр бораулап караганнар, юанлыгы мич морҗасы кадәрле бораuларын тимер чыбык урынына бөгеп кенә куйган ди. Тагын йөз елдан бу тирәләрне су басып, авыл бөтенләй юкка да чыгарга мөмкин икән әле. Кечкенә булсам да, кызыксыну бар миндә, һәр нәрсәнең төбенә төшергә тырышам, бу сөйләшүләр бер дә җанга ятышлы түгел, күңелгә шом салалар.

Абыйлар укудан кайталар да, йорт-каралты тирәсендә эшләрне карагач, урам башындагы яланга шылалар – нефтьчеләр тирәсендә уралалар. Тегеләре боларны куып та карыйлар икән, авыл малайларыннан алай гына котылырсың, ди менә. Абыйлар шул тирәдә тиккә йөрмиләр, нәзек кенә, тышы төрле төстәге бакыр чыбык кисәкләре алып кайталар өйгә. Сәйлән дип сөйләшәләр үзләренчә. Ал, яшел, сары, зәңгәр төсләләр, күз явын алырлык инде менә. Ничек кызыкмассың ди! Абыйлар шушы чыбык кисәкләреннән матур итеп йөзек үрергә өйрәнеп җибәрделәр, дөресрәге, бер Гришка атлы бригадирлары бар икән, Шәрифә апаларга фатирга кергән, шул йөзек үрү серләренә өйрәткән малай-шалайны.

Белүемчә, нефтьчеләр безнең урам башындагы яланга килеп, хуҗалыкларын корып җибәргәннәр. Беркөнне Шәрифә апа кереп, гаҗәп кызыклы хәл сөйләде: шул яланның уртасына бишка коралар икән. Гришка әйткән, аның башына менеп карасаң, Пучы күренәчәк икән. Пучының безнең район үзәге икәнен дә беләм мин. Нефть дигәнен дә. Дивардагы кара эшләпәле радио көн-таң атса, шул хакта сөйли. Әле җырлап та җибәрәләр:

*Һай ли Баулылыр,*

*Һәр эштә мактаулылар!*

Баулы дигән җирдә дә нефть тапканнар икән. Шәрифә апа авыз суын корыткан бишка дигәнен дә бик күрәсе килә. Быел бәбкәләрне Түбән очтагы атауда саклыйлар, Югары очтагы яланда актарылмаган җир калмаган икән. Атау безнең өйгә ераграк, аңынчы урамның икенче очына чыгарга, егермеләп йорт үтеп барырга кирәк. Йә туктаусыз үтеп торучы машина-трактор астына барып керер дип, мине ул елны бәбкә сакларга бөтенләй җибәрмәделәр. Бер яктан әйбәт, икенче яктан иркенлектә йөрергә өйрәнгән малайга гел өй тирәсендә уйнаган булып азаплану ялыктыргыч нәрсәгә әйләнде. Болай куркып ятып булмас, беркөнне аякка абыйның олы күн итеген киеп, югары очка сәяхәткә чыгып киттем.

Коймага сыланып кына барам, урамны адәм мәсхәрәсе (Шәрифә апа сүзе) иткәннәр, әле үткән ел гына яшел үләнгә төренеп, тип-тигез булып яткан урамны, машина тәгәрмәчләре ярып, тирән чокыр ясап бетергәннәр. Каршы яктагы Кәлимулла абыйларга да кереп йөрешле булмас инде болай булгач. Тәгәрмәч ярган эзгә төшсәң – минем ише малай-шалайны күмеп китә тирәнлеге.

Кызыксыну көчле, яланда нефть эзләүче абыйларның ни-нәрсә кыланып ятканнарын күрәсе килә. Шүрләсәм дә, үзебезнең яктан коймага елышып, яланга табан атлыйм. Ерак түгел инде ул, өч-дүрт йортны гына үтәсең дә, Печмән елгасы белән авыл арасындагы яланга килеп чыгасың. Машиналар үткәндә коймага елышып торам, аларның зурлыгы безнең өй чаклы гына бардыр – коймаларга тиям-тиям дип бара тәгәрмәч өстендәге канатлары. Шулай да артка борылу юк, эһ иткәнче яланга килеп чыктым. Йә Хода, кәртинкә дә кәртинкә (Мәхтүрә апа сүзе) – монда үзе бер авыл салып куйганнар икән инде. Бер якта машиналар тезелеп тора, каршы якта әллә нинди тимерләр тагылган тракторлар һәм… ялан уртасында биек манара калкып тора. Шәрифә апа әле генә төзи башлаганнар дигән иде, ике-өч көн эчендә күккә терәлеп тә тора бу бишка дигәннәре. Мондагы хәлне күреп, аяк буыннары йомшап, тез буыннары сыегайды. Моның ишене күргән бармы?.

Беренче сәяхәттән үк җирдә яткан сәйлән чыбык табып алып кайттым. Аннан инде нефтьчеләр тирәсендә бөтенләй үз кешегә әйләнеп беттем, әнкәй килеп алып кайтмаса, өйгә кайтуны онытып йөрим. Мондагы кызыклык, мондагы могҗиза, мондагы берсеннән берсе гаҗәп машиналар, берсеннән-берсе хикмәтлерәк тимер-томыр таулары – ничек аерылып китәсең ди! Нефть эзләүче абыйлар бишкага гына якын китермиләр менә. «Өскә менсәң, җил ияртеп китәр» – дип, бишка тирәсеннән куып кына торалар. Минем исә менеп, Пучыны күрәсем килә… Юк булмады, тәки бишкага менүдән мәхрүм иттеләр мине.

Соңыннан белдем – Шәрифә апаның «бишка» дигәне, җирне бораулау өчен җиһазландырылган вышка икән ул. Ә Шәрифә апа бишка сүзен теленнән дә төшерми. Әйткәнемчә, Гриша исемле бригадир Шәрифә апаларга фатирга кергән иде. Гел елмаеп, малай-шалайны үртәүдән тәм таба торган гүәрдиндәй гәүдәле, калын мыеклы, җитез хәрәкәтле абый иде ул. Берара Гриша дип йөргән абыебызны тора-бара Шәрифә апа Бишка дип йөртә башлады Озын буйлы, киң җилкәле, җилдә-яңгырда йөзе чуендай каралып беткән Гришка абыйга Бишка кушаматы тагылды да куйды бит. Барыбыз да аны Бишка дип кенә йөртә башладык.

Кайбер чакларда Шәрифә апа ямансулап килеп керә безгә.

– Бишка кайтмады, әрәмәдә бораулыйлар, анда бар икән нефть. Шунда кунып яталар. Черки талап үтерә торгандыр инде. Кайда гына башын салып йоклый торгандыр. Ул аларның вагунчик дигән алачыгының бер шыгы да юк бит… – дип аны кызганып, җәлләп тә утыра. Бишка дигәндә аның күзләре яктырып китә, йөзләренә алсулык тибеп чыга. Башкалар ничектер, мин моны сизеп торам. Аннан Бишка әйтте, бездә нефть яшь икән әле, тиз генә чыгара башламаслар. Болар эз генә салып куялар икән, тагын икенче якка күчеп китмәкчеләр ди. Бишкасыз нишләрсең инде, үткән атнада бер машина утын кайтарып аударды. И йорт җанлы да инде, ни эшләргә кирәк дип кенә тора!

Озак та үтми, Гришка абый белән Шәрифә апаның икәүләп кич клубка төшеп барганнарын күргәли башладым, Хәтта берсендә… Әйтсәң дә ярый

торгандыр инде, абзар артлап кына икесе бергә безнең мунчага кереп киткәннәрен шәйләп калдым. Бу хакта әнкәйгә әйтергә тел кычытса да, курыктым, серне эчкә бикләдем.

Сер дип инде, эчне тишеп бетермәде тагын, чишелде. Бишка белән Шәрифә апа, авыл советына барып язылышып кайтканнар икән. Табышканнар болар. Шулай итеп җизниле дә булып куйдым, әмма малай чакның бер хыялы тормышка ашмады: Шәрифә апаны кияүгә алып киткәндә олы капканы үзем ачармын дип йөри идем. Алар исә, җәяүләп кенә барганнар да кайтканнар авыл советына. Туйлары да артык шау-шулы булмады ахры. Берничә көннән, Сәхипҗамал әби кереп, әнкәйгә зарланып алды:

– Болай булмый бит инде, никахсыз-нисез, үз өемдә чит кеше тотарга… Әйттем Шәрифәгә, никахсыз яшәүгә бәхиллегем юк, – дидем. Бишкасы авыз ерып тик тора, Шәрифә аңлатты инде. «Ничек була соң ул никах, давай ясатып куябыз», – ди икән. Шәрифәне дә озак тотмас инде, үзе белән алып китәр. Хатын-кызлар да эшли икән анда, измә болгатып торалар диме. Шәрифә, караган да каткан инде шул адәмгә. Сөйләштеләр, чыш-пыш килделәр дә, өйләнешеп тә куйдылар. И-и хәзерге яшьләрне. – Сәхипҗамал түти ишеккә табан бер адым атлагач, кабат әнкәйгә табан борылды. – Әйт әле Мингаярьгә, боларга никах укысын. Бишкасы каршы түгел ди бит.

Әнкәй район газетасын караштырып утырган әткәйгә эндәште.

– Карт, сиңа әйтәм, икенче кавем кешесенә никах укырга ярыймы? Шәрифәбез никахсыз яшәп ята икән бит…

Әткәй риза булмаган тавыш белән әйтеп куйды:

– Яшәрләр инде… Иман калдымыни яшьләрдә. Никахсыз да яшәрләр…

Шул чагында Сәхипҗамал түтигә нидер булды, әткәй каршысына килеп өстәлгә таянды:

– Укы, Мингаярькәем, шуларга никах. Яшәтмә болай Шәрифәне. Үз күз алдында үскән бала бит ул… Мәдрәсә белемең бар, никахка гына җитәр әле.

Әткәй урыннан торды.

– Никах дигәч тә… Белсәләр, ник туганга үкенерсең! Заманы нинди бит. Иман-шәфкать калдымыни бәндәләрдә. Барып әләкләсәләр.

– Беркем дә белмәс, – диде Сәхипҗамал түти, тавышын әкренәйтеп. – Күреп торам, Шәрифә дә бәргәләнә. Әйт, никах өчен ни кирәк?

– Лә иллаһи кәлимәсен әйтергә тиеш бит кияү. Ризамы ул аңа? Безнең халык түгел бит.

– Риза дигән бит инде. Аннан ул гел татарлар арасында үскән, Бөгелмә ягыннан ди. Татарча да аз-маз сукалый. Шәрифә белән чөкердәшәләр инде, берсе татарча пупалый, берсе русча.

Кызыгы шул, никах укылганмы, юкмы, анысын мин күрми-белми калдым. Әмма Шәрифә апа бер көнне эткәйгә күлмәклек ситса кертеп чыкты.

– Абзыкай, кылган яхшылыгыңны мәңге онытмам, – диде ул дулкынланып. Минем кулга исә бер уч ирис конфеты һәм хушбуй аңкып торган чигелгән кулъяулык тоттырды.

…Бик күңелле тормыш башланган иде дә. Шәрифә апа Бишка сүзен теленнән дә төшерми иде. Язмышның үз кануннары, кайдадыр күрше районда эшләп йөргәндә торба ычкынып, Бишканы харап иткән.

Кара кайгы килде Шәрифә апага. Авырлы иде. Озак та үтмәде, тупырдап торган бер малай алып кайтуын хәбәр иттеләр. Бәбине күрше апабыз участок больницасында тапкан иде, берничә көннән Шәрифә апа бәбиен күтәреп өйләренә кайтып керде. Әнкәйгә ияреп мин дә бәби күрергә кердем.

– Бишка! Коеп куйган Бишка! – дип сөйләнә Шәрифә апа бишек тирәсендә. – Бу кадәр Бишка булыр икән, үзе тапса да болай ук булмас!

Әнкәй сәерсенеп, сорап куйды:

– Балаңа Бишка дип исем кушмассың бит инде, Шәрифә? Бишка да, Бишка… Шул да булдымы исем.

– Исемен уйлап куйган идек инде без аның, әле этисе исән чагында ук, – Шәрифә апа күзеннән сыпылып чыккан яшен сөртеп алды. – Дусты булган аның, Данил исемле. Татар малае, шәп егет иде ди. Малай булса, Данил дип

кушабыз дип йөргән иде. Кыз турында уйламадык та. Бишка ике сүзнең берендә: «Малайка, малайка», – ди торган иде, мәрхүмкәем.

Данил чая малай булып үсте. Әтисенә охшап, буйчан, әтисенә охшап йөзеннән елмаю китми.

…Институт тәмамлагач, хәрби кафедра белемен алучы буларак. мине бер елга ерак Көнчыгышка армия хезмәтенә җибәрделәр. Тынгысыз чагы иде чик буйларының, хезмәт вакыты тәмамлангач та ике-өч ай артык гарнизонда яшәргә туры килде.

Сентябрь урталарында гына авылга кайтып җиттем.

Өй турына җитәрәк, каршыма Шәрифә апа очрады. Башта, барган җиреннән туктап, танымаган сыман минем өске киемнәрне күздән кичерде, аннан ачылып китеп:

– Бәй, бәй, Фәридун түгелме соң син? – диде ул икеләнгәнрәк тавыш белән – Син армиядә идеңмени? Шаклар катып торам, армиядә икәнеңне искәсанга да алмаганмын. Эштән баш чыкмый бит авыл кешесенең, эш тә эш инде безгә. Күршеңнең армиядә икәнен дә белми яшә инде, вәт бәрәмәч!

Бу сүзләрдән кәефем төште. Ел ярым диярлек армия сафларында айтдвага йөреп кайткан күршеңне шулай каршы ал инде. Хәтта армиядә булуым да мәгълүм түгел авылдашларга. Мин исә ялт-йолт итекләр киеп, кәс-кәс атлап, хәрби киемнән урамнарны балкытып ашкынып кайтып килгән булам. Алар… белмиләр дә…

Күңел төште.

Шәрифә апа сөйләнүен дәвам итте:

– Кара әле, Фәридун, армия да үстерә алмаган сине. Җыйнак кына егет идең Казанда укып йөргәндә, һаман да шул җыйнак Фәридун икәнсең. Хикмәт диген, армия да үстерә алмый икән адәм баласын. Орлык нинди инде, орлык. Менә безнең Данилны күрсәң! Ике метрлы пәһлеван! Бишка инде, тач әтисе Бишка! Әле сине күргәч, уй килде башыма, минем Бишкага ничегрәк табарлар микән кием-салым. – Күзен чекрәйтеп янә миңа караш ташлады. – Сиңа табылган, син бит җыйнак, минем Бишкага ничек табарлар кием? Аягына

кигән итеге дә кырык алтылы бит аның. Әле армияга барганчы тагын күпме үсәр? Бишка инде, Бишка!

…Гомерләр үтә торды. Инде безнең нигездә дә башка кешеләр яши, Шәрифә апаны да, йортларын сатып, Данил Әлмәт якларына алып китте. Башта нефть техникумында укыды, аннан армия сафларында хезмәт итте ул. Беренчеләрдән булып Әфган җиренә аяк баскан солдатлардан булды. Шәрифә апаның чәчләре агарды ул чакта.

– Бишка бит, Бишка, таш арасына яшеренеп калырлык та түгел, ул-бу була калса, иң беренче пуле аны эзләп табачак. Инде исән генә кайтсын. Намазлык өстеннән төшмәде апабыз. Бәхетенә, кылган догалары кабул булды – Данил исән-имин кайтып керде өенә. Аннан Нефть-газ институтында укып, бүген инде ул шактый зур эштә икән. Начальник ди. Шәрифә апа да гүр иясе булган. Данил – Бишка авылны онытып бетерми икән, әле күптән түгел мәктәпнең түбәсен алыштырткан диделәр. Игелекле Бишка булып үскән, озын гомерле булсын инде.

**Номинация**
**«Поэзия на татарском языке»**

***Лилия Фаис кызы Гыйбадуллина***
*член Союза писателей РТ*

## ТАТАР НЕФТЕ

*(Цикл)*

Җәйрәп ята бодай басулары.
Язгы җилдә яшел дулкыннар.
Җир астында кайнар дәрья тоеп
кайный микән әллә ул кырлар?

Кыр түренә басты манаралар,
сискәндереп арыш басуын.
Кеше җирнең үзәгенә төште,
серен ачып миллион гасырның.
*Саҗидә Сөләйманова*

Сер тулы йомгактай җир шары
Тәгәри гасырдан-гасырга.
Ул серләр туфракка күмелгән,
Ул серләр күкләргә асылган.

Күкләрдән өзелеп төшкәнме,
Туфрактан өзелеп тамганмы –
Йолдызлар хикәят сөйлиләр –
Кара җир йөзенә язганны.

Борынгы хикмәтле хикәят
Ким түгел «Мең дә бер кичә» дән:
«Җир сыман кап-кара хак алтын
Саркыла икән лә чишмәдән.

Җир сыман кап-кара хак алтын
Сибелгән икән лә суларга,
Кап-кара дулкыннар чайкалып
Киләчәк көннәрне сугара.

Алтынга тиң кара туфракның
Төбендә тибенә-тибенә,
Сулкылдый-сулкылдый җир аслап,
Җир өсләп кара җыр түгелә.

Җыр булып яңа чор чаң суга,

Чаң булып яңа җыр җырлана.
Кешеләр ярыша-ярыша
Кара май сөзәләр елгадан.

Гасырдан-гасырга бу хәбәр
Дөньяга җил булып тарала.
Җир-Ана карнында тирбәлеп,
Өр-яңа юаныч ярала.

Вавилон, борынгы Мисырдан –
Хәбәрләр ерактан-ерактан:
Елгадан табылган кара май
Һәр эштә гамәлгә яраклы.

Нефть – бәлзәм, нефть – дәва, нефть – кәлга
Һәм утлы корал да дошманга.
Кешеләр күкләргә очына
Кешеләр туфракка ышана.

Җир өсләп, җир аслап җыр ага.
Чор ага, чорнала бугазга.
Кешеләр коелар казыйлар,
Кешеләр салалар буразна.

Калалар кыбырсып калкына,
Караңгы урамнар яктыра.
Тормышың җайланыр – җиреңнән
Кап-кара шул майны тап кына!»

Кара май – яктылык. Гөлт итеп
Тарихта лампалар кабына,
Җирдәге утларның яктысы
Йолдызлар катына кагына.

Чор күчә, ут күчә, җир – күчәр,
Күчәрдә сүрелми ут яна.
Гасырдан гасырга күчә ул –
Борынгы һәм кабат өр-яңа.

Кара май манылган таякта,
Кәрәчин салынган лампада,
Ут булып кешеләр өендә,
Нефть үзе җир өсләп яктыра.

Бу утлар яктырта дөньяны,
Караңгы төннәрне яктырта.
Җир каны – кара май яктысы
Ак булып сирпелә һәр йортка.

* * *

Шөгерләргә барам әле,
Шөгер суы тәмлегә.

*Татар халык җыры*

Авыл кешеләре бу сыекча белән арба күчәре майлыйлар иде. Кара чишмәдән чыккан кара сыекча белән майланган арба тәгәрмәче бик җиңел тәгәри.

*Гәрәй Рәхим*

Шыгыр-шыгыр килә җир күчәре,
Көе, җае, көне авырая.
Җир йөзендә сугыш, сугыш, сугыш…
Кай тарафка йөзне борырга, йә?!

Шыгыр-шыгыр килә җир күчәре.
Сыкрый-сыкрый әйләнгәндә җирең,
Борынгы бер сөаль сытылып чыга:
«Бу ватанда яшәү кемгә җиңел?»

«Бу ватанда яшәү кайчан җиңел?»
Шушы сорау тора җилдәй улап.
Ак кәфенлек төсле ак кылганнар
Йөгерәләр һаман дала буйлап.

Шыгыр-шыгыр… Майлап җибәрсәң лә,
Мае кирәк, мая кирәк көнгә!
Әйләнсен җир кояшлырак җайга,
Әйләнсен җир кояшлырак көйгә!

Ватан сугышы бара – бөек сугыш…
«Барысы да фронт өчен!» Гази[1]
Рейхстагка байрак кадаганчы,
Ничек тә түз, дөнья, билләһ газыйм…

[1] Рейхстагка тәүге җиңү байрагын кадаган Гази Заһитов.

Татар ире яуда сугышканда,
Татар җире тылда суырыла.
Барысы да фронт өчен кирәк!
Кирәк җирдән нефть суырырга!

Карыныңны каер, татар җире.
Йөрәгеңне каер, татар ире.
Бәгырь катламыңда катмар-катмар
Үткән тарихыңның зәмһәрире:

Зәһәрлеге җелекләргә үткән,
Түзсен генә, түзсен генә йөрәк.
Фронт өчен, уртак җиңү өчен…
Хәтәр барда татар һәрчак кирәк.

Суырып ала вакыт дигән чоңгыл,
Иләк аша или элеккене.
Җаны, җыры, җире – ватан өчен,
Ә үзе соң бу ватанның кеме?

Җир өсләтеп вакыт шуыша тора,
Җир аслатып кара чишмә ага,
Кара алтын тулы татар җире –
Сызлап тора, бәгырен ачып кара.

Шыгыр-шыгыр…
Шөгер туфрагында
Шөкер итеп яшәп яткан чишмә
Киләчәкнең серен илгә чишә,
Киләчәкнең серен җиргә чишә.

Шөгер, Шөгер! Җандур тавы[2] булып
Чал тарихың сакта торадыр ла.
Заманында җир читеннән килеп,
Тауларыңнын төбен тырнадылар.

Нефтьле җир дип бораулады күпләр,
«Нефтең бир!» дип бораулады заман.
Тамырыңда типкән бәрәкәткә
Кырык өчтә бәреп чыгу язган.

[2] 1870 елларда Америка сәнәгатьчесе Л.Шандор авыл территориясендә механика остаханәләре төзетә, нефть чыгару өчен 2 скважина бораулата. 1881 елда гудрон (битум) заводы ача. Аның янындагы тауны авыл халкы Җандур-тау дип атый башлый.

Мең тугыз йөз кырык өчтә бары,
Сулык-сулык торган чакта көнең,
Һәр тарафта иңрәп торган чакта
Кабер тынын бөркеп сугыш өне.

Кырык өчтә Шөгер басуыннан
Күтәрелгән тәүге скважинада
Ватан өчен, җиңү өчен дигән
Тәүге аваз – өр-яңа җыр ага –

Татар җыры! Татар туфрагында
Каралмас дан һәм кара кан сеңгән –
Әрнү төсле, әче өмет төсле
Кара алтын кубарыла җирдән.

Бәгыреннән өзеп татар җире
Канын бирә. Мәгез! Ватан өчен…
Сугыш дигән дәхшәт капкынының
Богауларын болгап ватар өчен,

Һәм торгызыр өчен ил-ватанны –
Сугыш соңра күтәрмәгә калган,
Һәм космоска юллар сузар өчен
Шөгер басуыннан нефть ага.

Шыгыр-шыгыр килгән җир күчәрен,
Күтәрелеп Шөгер басуыннан,
Кара алтын – татар нефте майлый.
Һәм беразга
чор җайлана сыман…

* * *

Егет булсаң, егетлек күрсәт илгә…

*Габдерәхим Утыз Имәни*

Күренекле татар шагыйре Утыз Имәни яшәгән Тимәш авылында, шагыйрь өеннән ерак та булмаган тау битендә, атаклы Ромашкино нефть чыганагын ачып җибәргән 3нче скважина 1948 елның июлендә девон ятмасындагы нефтьне көчле фонтан итеп күккә чөя. Ул тәүлегенә 120 тонна нефть бирә башлый һәм СССР нефть промышленностенда иң зур рекордлы скважина була.

*Гәрәй Рәхим*

Җилләренә тисәң – җирсенерсең,
Суларына тисәң – сугарыр,
Бу төбәкнең җире, җиле, суы –
Җаннарыңны җилпи торганы.

Җыру әйтсәң – көең таныр таулар,
Сүз эндәшсәң – таныр үзәннәр.
Илгә чәчәр якты йолдызларны
Күк тибрәтеп монда өзгәннәр.

Тиеп кенә, кагылып кына уза,
Кагып кына уза иңнәрдән –
Замананың җилбер-җилбер җиле
Алга таба әйдәп җибәрә.

Җырларыма тимәс булсаң гына,
Тимәс булсаң гына телемә,
(Билемдә бит балтам әзер тора…)
Кулларыңны сал син иңемә,

Заман җиле! Капкам ачык сиңа,
Ни соранып тагын килешең?
Тел төбеңдә һаман иске сөаль,
Үзгәрсә дә килбәт-килешең.

Төзелешләр арты төзелешләр,
Заводлары, биек йортлары,
Шәһәрләре, таш юллары кирәк –
Дәвер тынын буып тотарлык…

Иманыма тимәс булсаң гына,
Тимәс булсаң гына телемә,
Бәгыремне ярып, каным бирәм
Тимәш яны – татар җиреннән.

Тынлык тибрәп яткан басуларда,
Изрәп яткан үзән йөзендә,
Таулар үзәгенә, үләннәрдә
Кап-кайнар бер ташкын сизелә.

Җир өсләтеп заман җиле исә,
Җир аслатып кара җыр ага –
Миллион гасыр элек яралса да,
Ил иркендә әле өр-яңа.
Тимәш басуында скважина

Яңа тарих яза ватанга.
Елъязмага уелыр яңа исем
«Татар нефте» диеп атала.

Тимәш басуыннан бәреп чыккан
Татар нефте илне күтәрә,
Татар нефте яңа юллар яра
Һәм космоска күпер үткәрә.

Татар нефте хәрабәгә калган
Калаларны кора кабаттан.
Татар нефте машиналар төзи,
Татар нефте илне яңарта.

Кырык сигезенче елның июлендә,
Тибеп чыгып Тимәш басуын,
Җир белән күк арасында ургый
Йолдызларга гүя асылып.

Күккә чөя – яңа куәт илгә,
Күккә чөя кара җир канын,
Тик иминлек булсын туган җирдә,
Тик исән-сау булсын ватаным.

…Көлемсерәп тарих карап тора,
Башын кыңгыр салып җай гына.
Утыз Имәниләр ымы булып,
Иңнәреңә җайлап кагыла.

Каралмас дан һәм кара кан тамган,
Тетрәп торган татар җире бу.
Кылганнары ап-ак дога укып,
Тибрәп торган татар җире бу.

Бәгыреннән суырып җыр чишмәсен
Ил гаменә койган җирләр бу.
Иелеп сәлам иңдер. Җыруыңны
Таулар аңлар телдә җырлар бул.

Иелеп рәхмәт укы. Сүз эндәшсәң,
Сөйләмеңнән таныр таңнары,
Сәламеңне тыны белән тартып,
Кайтавазга кушар таулары.

Утыз Имәниләр ут тергезгән,
Тәкбир әйтеп торган туфрак бу.
Шуннан килеп, шуңа кайтасың бар –
Кунак булсаң җирдә, тыйнак бул.

Җанын тырнап ап-ак җырын койган,
Кара алтын койган чишмәләр
Мәңгелекнең моңлы өне булып,
Гади бер сер сиңа чишәрләр:

Туфрак өсләп ак кылганнар ага,
Туфрак аслап кара җыр ага,
Татар үзе, татар сүзе сыйсын
Татар нефте сыйган дөньяга!.

Кара алтын булып татар җаны,
Татар рухы ага, аңласаң.
Үзен, сүзен, телен данла аның,
Җырын данла, малын данласаң.

Бер карасаң, дөнья кара кебек,
Ага кебек чишмә җаена.
Ак яулыгын ябып аткан таңнар,
Керләнә дә төнгә ябына.

Бер карасаң, мең карасаң, мәңге…
Зәңгәр күк һәм туфрак арасын,
Сер йомгагы итеп бу җир шарын,
Барасы да һаман барасы.

Җилләренә тисәң – җирсенерсең,
Суларына тисәң – сугарыр,
Бу дөньяның җире, җиле, суы –
Җаннарыңны җилпи торганы.

Җилпеп кенә узган заман җиле,
Әйләнә дә кайта кай ара.
Җир күчәре һаман шыгыр-шыгыр –
Татар нефте кирәк дөньяга…

## Номинация
## «Поэзия на татарском языке»

*Ландыш Альберт кызы Габдрахманова*

### КАРА БАТЫР

*(Поэма)*

***Хан заманы***
Гасырларны берәм-берәм
Тарихлардан эзләп табыйк.
Чор үтсә дә, язу кала,
Димәк, юллар түгел ябык.

Кара Батыр мең ел элек
Җир астында тамыр җәйгән.
Үз куәтен исбатларга
Сорамаган ачык мәйдан.

Тәрәзәче Петр Берләр,
Галиҗәнап Әби патша…
Кара Батыр барысының
Хыялында чынга аша.

Уразмәтләр нәселенең
Надир атлы бер угланы
Озак эзләгән, имештер,
Кара Батыр хак юлларын.

Бирешмәгән Кара Батыр.
Еллар арты еллар узган.
Фидакарьләр «чабатасы»
Әрдәнәләп, имеш, тузган.

Океан арты галимнәре
Хыялланган булса кирәк,
Кара Батырны тиз генә
Чыгарырбыз диеп сөйрәп.

Ансат кына бирешмибез,
Холык шундый, нишләтәсең.
Мәйдан тотыйм дисәң, әгәр,
Баш батырга көрәшәсең.

***Көрәш***
Адәм басмаган урында
Сукмак салу гаять авыр.
Шуңа өстәп, килеп чыкса
Күз күрмәгән яңа давыл.

Кара Батыр тирәндәрәк,
Анда – сугыш, монда – сугыш.
Хыял өчен жәл түгел ул
Туккән көчең, алган сулыш.

Ватан көтсә синнән җиңү,
Батырларга тиңләшерлек.
Ил дошманы белән яуда
Акыл җигеп көрәшерлек.

Ил язмышы кыл өстендә,
Синең өстә изге бурыч.
Йөрәгеңдә көч барында
Мең тапкырлар күбрәк тырыш.

Җир-Ана дип юкка гына
Әйтмәгәндер бездә халык.
Ярдәменнән ташламый ул,
Сөйләшә бел җаен табып.

Иң катлаулы мәлләрдә дә
Шатлык тулы килә хәбәр:
Көчлеләргә көч бирим дип,
Кара Батыр ишек кагар.

***Күрешү***
Ургылды көч, бәрде куәт,
Кара Батыр көнгә чыкты.
Ышанмаган өметсезне
Җиле белән җиргә екты.

Һәм таралды илгә шөһрәт,
Пәһлеванга мактау яуды.
Һәрвакытта хаклык өстен,
Дошман чүкте, дошман ауды.

Ничә гасыр хыял булган
Ул көн килде киләчәктән.
Бу мәлдәге тырышларны
Дан-шөһрәткә күмәчәкләр.

Тәкыядәге гөлләр кебек
Тезелеште зур җиңүләр.
Кара Батыр әй кинәнде,
Акландылар бу көтүләр.

Татар илен колачлады,
Каһарманның күңеле киң.
Булыр микән тагын берәү
Аңа тиңдәш, аңарга тиң?

Янартаудай күккә ашты
Җир бәгыреннән кара алтын.
Батыр булыр күпме ирнең
Йөрәгенә капты ялкын.

***Үр арты үр***
Үзәнлекләр, калкулыклар
Кара Батыр ишеме соң?
Үрләр аша офыкларга
Синең җырың ишетелсен!

Алкышларны, дан-шөһрәтне
Кем яратмый җир йөзендә?
Мактасалар, уздырырсың
Соңгы көчкә үзеңне дә!

Һәм уздыра Кара Батыр,
Тарих яза киләчәккә.
Һәм ышана, килер буын
Үзен күккә чөячәккә.

Ышанды ул. Ышандылар.
Акландылар өметләр дә.
Инде күптән чал кунгандыр
Ул чактагы егетләргә.

Үрләр яулау җиңел түгел,
Тик иң авыр үрдә калу.
Көчең беткән чагыңда да
Егылмаска куәт табу.

Кара Батыр тауга менгәч
Көч-дәрманын ныгыткандыр.
Үзәнлектә үзен-үзе
Тауга карап юаткандыр.

Уйлагандыр: килер ул көн,
Хуҗа булыр акыл көче.
Шул чагында юмарт булыр
Кешелеккә җирнең төше.

***Акыл гасыры***
Үтте ул чор, күзне йомып,
Хуҗаларча җирне яулау.
Иртәгене искә алмый,
Бүгенгедән барын даулау.

Кара Батырга янәшә
Килде акыл, килде заман.
Билен бирде дигән Батыр
Әле һаман тота мәйдан.

Ил тоткасы булыр ирләр
Акыл белән көйли эшен.
Бүген түккән маңгай тирең
Киләчәккә илтсен өчен.

Җирдән чыккан алтын әүвәл
Баетсын дип рух дөньясын
Хезмәт итә икән кеше,
Тапкан димәк, чын кыйбласын.

Кара Батыр бүген дә бит
Ватанымның таянычы.
Шушы җирдә туганнарның
Килер көнгә ышанычы.

Еракларга җитәр һәрчак
Үз илемнең яхшы аты,
Көч-куәте, горурлыгы
Булган чакта Кара Батыр!

**Номинация**
**«Проза на русском языке»**

***Фархутдинов Ильгиз Михайлович***

## ПОРЫВ НА НЕФТЕПРОВОДЕ

*(Рассказ)*

Бурая и почти черная от ярости, скованная в толще земных пород, набиралась она сил, чтобы через тысячелетия просочиться, пропитывая каменную массу, наверх к солнцу или притаиться неподвижно на карбомитном ложе и ждать той секунды, когда алмазное долото избавит ее от плена. С оглушительным ревом и визгом взовьется она радужно-черным фонтаном над землей, но тут же, втиснутая в трубы, последний раз еще судорожно тряханет арматуру и спокойно потечет по магистралям. Этот энергетический коктейль, который люди назвали нефтью, силен и агрессивен… Марат стоит на опушке леса. Только что он выкатился из чащи на своих широких охотничьих лыжах и замер от увиденного.

